**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 5 сентябрендәге 2804 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 18 февралендәге 381 номерлы «Казан шәһәре территориясендә пиротехник эшләнмәләрне куллануны (фейерверк тамашалары үткәрүне) тәртипкә салу чаралары турында»гы карарына үзгәреш кертү хакында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2025 елның 3 февралендәге 90 номерлы «Россия Федерациясендә Янгынга каршы режим кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында»гы карары, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге вәкиллекле органының 2005 елның 17 декабрендәге 3-5 номерлы карары белән расланган Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 43 статьясы нигезендә, пиротехник эшләнмәләр кулланып, фейерверклар һәм башка массакүләм тамаша чаралары үткәргәндә кешеләрнең тормышы һәм сәламәтлеге куркынычсызлыгын тәэмин итү, муниципаль милеккә, юридик һәм физик затлар милкенә зыян китерүне булдырмау максатыннан **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 18 февралендәге 381 номерлы «Казан шәһәре территориясендә пиротехник эшләнмәләрне куллануны (фейерверк тамашалары үткәрүне) тәртипкә салу чаралары турында»гы карарының 2 номерлы кушымтасына, 5 пунктның өченче абзацында «өстәмә инженер-техник чаралар» сүзләрен «оештыру-техник чаралар» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru), Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 сентябреннән гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкче вазифаларын башкаручы –**
**беренче урынбасар** **А.Р.Нигъмәтҗанов**